| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 Олы Кайбыч ав. № 14

Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче хуҗалардан башка хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарның беркетелгән исемлеген расларга
2. Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге территориясендә хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле вәкил итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулайук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге https://bkaybic-kaybici.tatarstan.ru/веб-адресы буенча

Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф.Әхмәтов

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 21 нояренең 14 номерлы
карарына кушымта

Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар
ИСЕМЛЕГЕ

- гомуми файдаланудагы территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, машина юллары, парклар, скверлар һәм башка территорияләр, алар белән чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана);
- күп фатирлы йортларга якын территорияләр;
- балалар өчен уен һәм балалар спорт мәйданчыклары;
- актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
- массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
- балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
- мәдәният объектларына якын территорияләр;
- җәмәгать туклануы оешмаларына, кибетләргә якын территорияләр.